ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2024 ел Баулы шәһәре №149

Бавлы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 апрелендәге 112 номерлы, 2023 елның 24 августындагы 172 номерлы, 2024 елның 9 августындагы 106 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2024 елның 25 октябрендәге 86-ЗРТ номерлы «Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 3.2 һәм 3.16 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында» Законын үтәү белән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Бавлы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 апрелендәге 112 номерлы, 2023 елның 24 августындагы 172 номерлы, 2024 елның 9 августындагы 106 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 3.16 маддәсе» юлында маддә атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 3.16. Түләүле муниципаль парковкалардан куллану тәртибен бозу (парковка урыннары)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров